Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Минзәлә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Минзәлә муниципаль районы составына керүче "Аю авыл җирлеге" һәм "Юртово авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен "Юртово авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең "Аю авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге, "Воровский исемендәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге һәм "Яңа Мәлкән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә урнашкан басу аша кишәрлеген "Аю авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе составына кертү юлы белән үзгәртергә.

**2 статья**

"Минзәлә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (IV өлеш); 2008, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) өченче абзацта "Маткауш," сүзеннән соң "Дружба," сүзен өстәргә;


б) унтугызынчы абзацта ", Дружба авылы" сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Минзәлә муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Минзәлә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре

## карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 17(19)-16(А) | - Удмурт Республикасы |
| 16(А)-1(67) | - Әгерҗе муниципаль районы |
| 1(67)-31(68) | - Тукай муниципаль районы |
| 31(68)-33(69) | - Сарман муниципаль районы |
| 33(69)-25(70) | - Мөслим муниципаль районы |
| 25(70)-17(19) | - Актаныш муниципаль районы |

"Минзәлә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Минзәлә шәһәре |
| 2 | Әтрәкле авыл җирлеге |
| 3 | Аю авыл җирлеге |
| 4 | Бикбау авыл җирлеге |
| 5 | Югары Тәкермән авыл җирлеге |
| 6 | Воровский исемендәге авыл җирлеге |
| 7 | Иркәнәш авыл җирлеге |
| 8 | Кадрәк авыл җирлеге |
| 9 | Коноваловка авыл җирлеге |
| 10 | Хуҗамәт авыл җирлеге |
| 11 | Наратлы Кичү авыл җирлеге |
| 12 | Николаевка авыл җирлеге |
| 13 | Яңа Мажын авыл җирлеге |
| 14 | Яңа Мәлкән авыл җирлеге |
| 15 | Тауасты Байлар авыл җирлеге |
| 16 | Иске Мажын авыл җирлеге |
| 17 | Иске Матвеевка авыл җирлеге |
| 18 | Ырыс авыл җирлеге |
| 19 | Юртово авыл җирлеге |
| 20 | Юшады авыл җирлеге"; |

3) 5 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аю авыл җирлеге Бикбау, Воровский исемендәге, Николаевка, Яңа Мәлкән, Иске Мажын һәм Иске Матвеевка авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аю авыл җирлеге чиге Яңа Мәлкән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аю, Бикбау һәм Яңа Мәлкән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Куян авылыннан 2,0 км төньякта урнашкан 22 нче тоташу ноктасыннан алып 4,6 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре. буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 650 м, аннары төньяк-

көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,65 км көньяк-көнбатыш юнәлештә "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 113, 115 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары төньяк-көнбатышка таба 710 м шушы урманчылыктагы 114 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң, автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 720 м шушы урманчылыктагы 116 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, автомобиль юлын һәм Дарьянка елгасын кисеп үтеп, гомуми юнәлештә 6,7 км төньяк-көнбатышка таба шушы урманчылыктагы 116, 110 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап Аю, Воровский исемендәге һәм Яңа Мәлкән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 660 м көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Аю авыл җирлеге чиге Воровский исемендәге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 26 нчы тоташу ноктасыннан алып 950 м төньяк-көнчыгышка таба "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 5 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап аның төньяк почмагына кадәр уза, аннары гомуми юнәлештә 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасының көньяк-көнчыгыш кырые буенча бара, аннары 530 м көньяк-көнчыгышка таба "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 240 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м шушы урманчылыктагы 107 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 107 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 410 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

г) унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

4) 8 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Юртово" сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацта "Воровский исемендәге, Яңа Мәлкән авыл җирлекләре һәм Юртово авыл җирлегенең басу аша кишәрлеге чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Аю, Воровский исемендәге һәм Яңа Мәлкән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Воровский исемендәге авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Аю, Воровский исемендәге һәм Иске Маҗын авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 1,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасыннан алып 950 м төньяк-көнчыгышка таба "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 5 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап аның төньяк почмагына кадәр уза, аннары гомуми юнәлештә 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, шуннан соң 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман полосасының көньяк-көнчыгыш кырые буенча бара, аннары 530 м көньяк-көнчыгышка таба "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 177 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 240 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м шушы урманчылыктагы 107 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 107 нче урман кварталының аерымланган массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 410 м төньяк-көнчыгышка таба, аннары көньяк-көнчыгышка таба 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 24 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

5) 16 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта ", Юртово" сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Яңа Мәлкән авыл җирлеге чиге Аю авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 4,6 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба 650 м, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң, автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,65 км көньяк-көнбатыш юнәлештә "Минзәлә урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Минзәлә участок урманчылыгындагы 113, 115 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, аннары төньяк-көнбатышка таба 710 м шушы урманчылыктагы 114 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң, автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 720 м шушы урманчылыктагы 116 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары, автомобиль юлын һәм Дарьянка елгасын кисеп үтеп, гомуми юнәлештә 6,7 км төньяк-көнбатышка таба шушы урманчылыктагы 116, 110 нчы урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк чикләре буйлап Аю, Воровский исемендәге һәм Яңа Мәлкән авыл

җирлекләре чикләре тоташкан урында Дружба авылыннан 660 м көнчыгышта урнашкан 24 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 21 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Юртово авыл җирлеге "Минзәлә шәһәре" муниципаль берәмлеге, Коноваловка, Тауасты Байлар һәм Иске Маҗын авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) сигезенче – унберенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 29-ТРЗ